РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КОРСАБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

422051, Республика Татарстан, Сабинский район,
с.Корсабаш, ул. Школьная, 28
тел. (84362) 2-27-49

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ КУРСАБАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422051, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Курсабаш авылы, Мәктәп урамы, 28 йорт

тел. (84362) 2-27-49

e-mail: korsab.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ                                                                 КАРАР

01.04.2019                                                                 №14

Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт
ителми торган биналарга, корылмаларга,
бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында

1995 нче елның 22 нче ноябрендә кабул ителгән 171 нче номерлы «Этил спирты, алкогольле һәм спиртлы продукция җитештерүне һәм әйләнешен дәүләт тарафыннан тәртипкә салу турында» Федераль законның 16 нчы матдәсе нигезендә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 нче елның 27 нче декабрендә кабул ителгән 1425 нче номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган гражданнарның күпләп җыелу урыннарын һәм югары дәрәҗәдәге куркыныч чыганаклары урнашу урыннарын Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары тарафыннан билгеләү, шулай ук алкогольле продукцияне ваклап сатарга ярамый торган кайбер оешмалар һәм объектлар янындагы чикләрнең җирле үзидарә органнары тарафыннан билгеләү турында» карары, ТР Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 2019 елның 25 нче мартында кабул ителгән 7 нче номерлы "Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннар турында" карары нигезендә,Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР ИТТЕ:

1. Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган түбәндәге территорияләрнең схемаларын расларга:

1.1. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш төп гомуми белем бирү мәктәбе" МБУУ , "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш "Кояшкай" балалар бакчасы" МБМБУ якын-тирә территорияләренең схемасын;

1.2. КФҮ - "Саба үзәкләшкән авыл клублары системы" №9 филиалы (Курсабаш мәдәният йорты), "Саба үзәкләшкән китапханәләр системасы" МБУ №14 филиалы Курсабаш авыл китапханәсе һәм Курсабаш авыл җирлеге Башкарма комитеты якын-тирә территориясе;

1.3. Курсабаш фельдшер-акушерлык пункты якын-тирә территориясе;

1.4. "Саба үзәкләшкән авыл клублары системасы" №38 филиалы (Түбән Утар авыл клубы) якын-тирә территориясе;

1.5. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш "Кояшкай" балалар бакчасы" МБМБУ филиалы-"Түбән Утар балалар бакчасы" һәм Түбән Утар фельдшер-акушерлык пункты якын-тирә территориясе;

1.6. "Саба үзәкләшкән авыл клублары системасы" №45 филиалы (Сүлә авыл клубы)

якын-тирә территориясе.

1.7. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының «Акылга зәгыйфь балалар өчен Югары Утар балалар интернат-йорты» дәүләт автоном учреждениесе янындагы территория схемасы.

2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлеге Советының 2017 нче елның 30 нчы ноябрендә кабул ителгән 22а номерлы «Алкогольле продукцияне ваклап сату рөхсәт ителми торган биналарга, корылмаларга, бүлмәләргә якын урыннарның схемасын раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Курсабаш авыл җирлегенең рәсми сайтында һәм җирлекнең информацион стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Курсабаш авыл җирлеге башлыгы: А.Р. Гыймадиев